ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
УРМАНЧЕЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Ленина, д.5, п.Зверосовхоза,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422186

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ УРМАНЧЫ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
Ленин ур., 5 нче йорт, Җәнлек совхозы поселогы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422186

тел.(факс): (85563) 2-12-50; e-mail: Urman.Mam@tatar.ru, www:mamadush.tatarstan.ru

**Карар** **Постановление**

**№ 116** **от 18 июля 2023 ел**

Мамадыш муниципаль районы Урманчы авыл җирлеге башкарма комитетының баш бухгалтеры хезмәтенә, муниципаль хезмәткәрләр вазыйфаларына кертелгән вазыйфалардан тыш, түләүне оештыру һәм аның шартлары турындагы нигезләмә хакында

Россия Федерациясе Хезмәт кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Мамадыш муниципаль районы Урманчы авыл җирлеге Башкарма комитеты турындагы Нигезләмә нигезендә Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Урманчы авыл җирлеге башкарма комитеты

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Мамадыш муниципаль районы Урманчы авыл җирлеге башкарма комитетының баш бухгалтеры хезмәтенә, муниципаль хезмәткәрләр вазыйфаларына кертелгән вазыйфалардан тыш, түләүне оештыру һәм аның шартлары турындагы нигезләмәне расларга.
2. Әлеге карар 2023 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.
3. Штат расписаниеләрен һәм локаль актларны әлеге нигезләмәгә туры китерергә.
4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматларының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Мамадыш муниципаль районы Урманчы авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштырырга.
5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет җитәкчесе А.Я.Ильин

Мамадыш муниципаль
районы Урманчы
авыл җирлеге
Башкарма комитеты карарына
Кушымта
" 18" июль 2023 ел, №116

# Мамадыш муниципаль районы Урманчы авыл җирлеге башкарма комитетының баш бухгалтеры хезмәтенә, муниципаль хезмәткәрләр вазыйфаларына кертелгән вазыйфалардан тыш, түләүне оештыру һәм аның шартлары турындагы нигезләмә

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Нигезләмәнең Россия Федерациясе Хезмәт кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Мамадыш муниципаль районы Урманчы авыл җирлеге Уставы нигезендә эшләнгән.

1.2. Әлеге Мамадыш муниципаль районы Урманчы авыл җирлеге башкарма комитетының баш бухгалтеры хезмәтенә, муниципаль хезмәткәрләр вазыйфаларына кертелгән вазыйфалардан тыш, (алга таба- бухгалтерлар) түләүне оештыру һәм аның шартлары турындагы Нигезләмә бухгалтерларның эшчәнлеген оештыруның аерым мәсьәләләрен регламентташтыра һәм хезмәткәрләрнең вазифа окладларын, компенсация һәм стимуллаштыру характерындагы түләүләр күләмен һәм аларны бирү шартларын билгели.

2. Мамадыш муниципаль районы Урманчы авыл җирлеге башкарма комитетының баш бухгалтеры хезмәтенә, муниципаль хезмәткәрләр вазыйфаларына кертелгән вазыйфалардан тыш, түләү.

2.1. Бухгалтер хезмәте өчен түләү вазыйфаи окладтан, тиешле елларны эшләгән өчен хезмәт хакына айлык өстәмә түләүдән, эш интенсивлыгы, акчалата бүләкләү, матди ярдәм күрсәтү һәм еллык түләүле отпускны биргәндә бер тапкыр түләнә торган түләү, эш нәтиҗәләре буенча премияләр алу өчен айлык хезмәт хакына айлык өстәмә түләүдән тора.

2.2. Бухгалтерның вазыйфаи окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| вазифа | муниципаль берәмлекләрнең башкарма комитетлары халык саны буенча | |
|---|---|---|
| | 3,5 мең кешегә кадәр | 3,5 мең кешедән артык |
| баш бухгалтер | 19 700 сум | 21 000 рублей |

| | | |
|---|---|---|
| Бухгалтер | - | 18 500 рублей |

Муниципаль берәмлекләрнең башкарма комитетларының штат расписаниесенә бухгалтер вазифасын кертү шарты булып муниципаль берәмлек халкының саны 3,5 меңнән артык кеше булуы тора.

2.3. Бухгалтерларга билгеләнә:

1) тиешле еллар эшләгән өчен вазыйфаи окладка ай саен түбәндәге күләмнәрдә өстәмә:

| эш стажы | Айлык өстәмә, процент |
|---|---|
| 1 елдан алып 5 елга кадәр | 5 |
| 5 елдан алып 10 елга кадәр | 7 |
| 10 елдан алып 15 елга кадәр | 10 |
| 15 елдан артык | 15 |

2) вазыйфаи окладның 10 проценты күләмендә эш интенсивлыгы өчен вазыйфаи окладка айлык өстәмә түләү;

3) вазыйфаи окладның ике проценты күләмендә айлык акчалата бүләкләү;

4) еллык түләүле отпуск биргәндә вазыйфаи окладның 120 проценты күләмендә бер тапкыр түләнә торган түләү;

Календарь ел дәвамында бухгалтерларга еллык түләүле отпуск бирелмәгән очракта, бер тапкыр түләнә торган түләү, эштән чыгарылган очракта - соңгы эш көненнән дә соңга калмыйча, декабрьдә, башкарылган вакытка пропорциональ рәвештә түләнә.

Еллык түләүле отпуск биргәндә бухгалтерларга бер тапкыр түләнә торган түләү календарь елда пропорциональ эшләнгән вакытка пропорциональ рәвештә башкарыла. Эшләнгән вакыт агымдагы календарь елның 31 декабре буенча эшкә кергән көннән исәпләнә.

5) хезмәткә түләүнең билгеләнгән фонды чикләрендә матди ярдәм;

6) хезмәт өчен түләүнең билгеләнгән фонды чикләрендә эшләү нәтиҗәләре буенча премия (премия күләме хезмәткәр эшчәнлеге нәтиҗәләреннән чыгып билгеләнә һәм максималь күләм белән чикләнми.

2.4. Бухгалтерларга һөнәр берләштергән, хезмәт күрсәтү зоналарын киңәйткән һәм, үзләренең төп эше белән беррәттән, хезмәткә түләүнең

билгеләнгән фонды чикләрендә төп эш буенча вазыйфаи окладның 50 проценты күләмендә билгеләнгән вазыйфаи окладны үтәгән өчен өстәмә түләү билгеләргә.

2.5. Бәйрәм һәм ял көннәрендә хезмәткәрләргә хезмәт өчен түләү, тиешле еллар эшләгән өчен хезмәт хакына айлык өстәмә түләүләрне эш интенсивлыгын исәпкә алып, биләгән вазыйфасы буенча акчалата бүләкләү икеләтә хезмәт хакы күләмендә башкарыла.

2.6. Хезмәт өчен түләүнең билгеләнгән фонды чикләрендә хезмәткәрләргә юбилей датасы, никахлашу, баланың туу, уллыкка (кызлыкка) алу уңаеннан, хатынының (иренең) вафат булуы уңаеннан, балаларның, ата-аналарның үлүе уңаеннан бер тапкыр бирелә торган матди ярдәм күрсәтелергә мөмкин.

2.7. Бухгалтерларның хезмәт хакының еллык фонды түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$FOT = \sum_{1}^{n}((O_d + 0{,}3 * O_d) * k) * (1 + t) + \sum_{1}^{n} \mathrm{P} * (1 + t);$$ монда:

$FOT$- бухгалтерларның еллык хезмәт хакы фонды;

$O_d$- бухгалтерга хезмәт хакын түләүгә акча суммасы;

$0{,}3 * O_d$- тиешле елларны эшләгән өчен хезмәт хакына айлык өстәмә түләүгә, эш интенсивлыгы, акчалата бүләкләү, еллык түләүле отпускны биргәндә бер мәртәбә түләнә торган түләү, матди ярдәм күрсәткән өчен вазыйфаи окладка айлык өстәмә түләүгә акчалар суммасы;

Р - бухгалтерларның еллык премия фонды (әлеге Нигезләмәнең 2 пунктының 5 пунктчасында билгеләнгән шартлардан чыгып билгеләнә торган);

$n$- бухгалтерларның штат саны;

$k$- 12 ай;

$t$- хезмәт өчен түләү буенча түләүләр.

### 3. Хезмәткәрләргә башка өстәмә түләүләр

3.1. Эш бирүче (яллаучы вәкиле) хезмәткәрләргә гамәлдәге законнарда билгеләнгән очракларда һәм тәртиптә башка өстәмә түләүләр түләргә хокуклы.